**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(84378) -3-54-22
факс: 8-(84378) -3-54-22

**ГЛАВА АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422613 н.п. им. «25 Октября»
тел: 8-(4378) -3-54-22
факс: 8-(4378) -3-54-22

2023 елның 8 ноябре 13 номер

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең Бутыри торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә Бутыри торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 12 ноябрендә 11 сәгать 30 минутка билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Бутыри торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Бутыри торак пунктында Үзәк, Степная урамнары буенча урам юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм тоту (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү) ;

Бутыри торак пунктының җәйге вакытта территориясен чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- янгын гидрантын урнаштыру;

су күтәрү манарасы коймасы;

- урам яктырту ;.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында  һәм  Александр авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә  халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы: Ю.Г.Трифонова**